**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Совет мәйданы, 14
телефон:(84366) 3-00-33,факс: 3-14-33, e-mail: 16T.009@tatar.ru

# К А Р А Р

14.03.2016 № 26

**2016 елның 13 мартында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе **2016 елның 13 мартында** узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

“2016 елда Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү | - Илдус, Угез-Елга авыллары өчен янгын сүндерү сыешлыклары сатып алу ; янгын сүндерү гидранты урнаштыру. | 20000 |
| 2 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Шушмабаш авылында су скважинасы бораулау,<br>- Шекә авылында суүткәргеч челтәр сузу; | 60000<br>20000 |
| 3 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда юлларны вак таш-лау; | 335490 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 4 | Җирлек территория-сен төзеклəндерүне оештыру | - Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктлар өчен аншлаглар əзерлəү . | 9460 |
| 5 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һəм транспортлау эшчəнлеген оештыру | - вакытлыча корыла торган урыннарны тоту, Шушмабаш авыл җирлеге составына керə торган барлык торак пунктларда каты коммуналь калдыкларны җыю һəм чыгаруны оештыру; | 10000 |
| | | Барлыгы: | 454950 |

Аерым мəсьəлəлəр буенча экономия барлыкка килгəн очракта, аерым мəсьəлəлəр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгелəнгəн башка мəсьəлəлəрне хəл итүгə акча җибəрергə рөхсəт итəргə".

Референдум нəтиҗəлəре турында беркетмə нигезендə:

референдумда катнашучылар исемлегенə тавыш бирү тəмамлануга 1681 референдумда катнашучы кертелгəн;

референдумда катнашучылар саны 1637, бу 97,38 процент тəшкил итə;

Тавыш бирү нəтиҗəлəре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбəндəгечə бүленде:

«əйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 1552 кеше тавыш бирде, бу 94,81 процент тəшкил итə;

«юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 85 кеше тавыш бирде, бу 5,19 процент тəшкил итə.

Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендə җирле референдумны узган дип таныргa, ə референдум нəтиҗəлəре гамəлдə дип таныргa.

2. Мəсьəлə буенча карар кабул итəргə:

"2016 елда Шушмабаш авыл җирлеге территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн балигъ булган һəр кешедəн 300 сум, көндезге бүлектə укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтəн өлкəнрəк кешелəрдəн 150 сум күлəмендə үзара салым кертелүгə һəм җыйналган акчаның түбəндəге җирле əһəмияттəге мəсьəлəлəрне хəл итүгə тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле əһəмияттəге мəсьəлəнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күлəме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тəэмин итү | - Илдус, Угез-Елга авыллары өчен янгын сүндерү сыешлыклары сатып алу ; янгын сүндерү гидранты урнаштыру. | 20000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Шушмабаш авылында су скважинасы бораулау,<br>- Шекә авылында суүткәргеч челтәр сузу; | 60000<br>20000 |
| 3 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда юлларны вак таш-лау; | 335490 |
| 4 | Җирлек территория-сен төзекләндерүне оештыру | - Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктлар өчен аншлаглар әзерләү . | 9460 |
| 5 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру | - вакытлыча корыла торган урыннарны тоту, Шушмабаш авыл җирлеге составына керә торган барлык торак пунктларда каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгаруны оештыру; | 10000 |
| | | Барлыгы: | 454950 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

3. Җирле референдумның гомуми нәтиҗәләрен Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе — Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре — Л.И. Нурмиева